ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
___________________

**К А Р А Р**
№ _______

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Биектау авылы территориясенең бер өлешен планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын раслау турында**

**(16:16:080507 кадастр кварталында урнашкан җир кишәрлекләре)**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 апрелендәге 361 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы территориясен планлаштыру проектларын, территорияләрне ызанлау проектларын әзерләү, территорияне планлаштыру проектларын, территорияләрне ызанлау проектларын тикшерү һәм раслау турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә, Биектау авыл җирлеге Советы үткәргән Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге, Биектау авылы территориясенең бер өлешен планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын раслау буенча 2025 елның 30 гыйнварындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап (16:16:080507 кадастр кварталында урнашкан җир кишәрлекләре), Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге адресы буенча урнашкан Татарстан Республи-

касы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Биектау авылы территориясенең бер өлешен планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын расларга (16:16:080507 кадастр кварталында урнашкан җир кишәрлекләре).

2. Әлеге карарны, кызыл сызыкларның характерлы нокталары координаталары исемлегеннән тыш (кызыл сызыклар күрсәтелгән план проекты сызымына кушымта) (хезмәттә куллану өчен материаллар) Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнашырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Р.Ш. Хисаметдиновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин